ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2024 г.Казань № 307-16/т-2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә 2025 елга максималь тарифлар һәм җыемнар билгеләү турында» 17.07.2024 ел, №42-5/т-2024 карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләре (тарифлары, җыемнары) дәүләт тарафыннан җайга салына торган аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләре исемлегенең 3 пунктына үзгәреш кертү турында» 2023 елның 28 сентябрендәге 1591 номерлы, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2024 елның 29 августында 1175 номерлы карарларын кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 31.10.2024 ел, №23-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә 2025 елга максималь тарифлар һәм җыемнар билгеләү турында» 17.07.2024 ел, №42-5/т-2024 карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «авиация» сүзен «транспорт» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «аэровокзал комплексы» сүзләрен «аэровокзал (терминал)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев